**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«14» 12. 2018 ел** **№ 345**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2019 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау муниципаль адреслы программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планы турында» 2016 елның 8 декабрендәге 361 номерлы карары белән расланган 2017-2019 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау муниципаль адреслы программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планы хакында карарына үзгәрешләр кертү турында ( 02.06.2017 №143 03.10.2017 №253, 25.07.2018 №148 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 4 маендагы 115 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль адреслы программага үзгәрешләр кертү турында», Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 31 декабрендәге 337 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль адреслы программасын» гамәлгә ашыру максатыннан **карар бирәм:**

1. 2017-2019 елларга Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау муниципаль адреслы программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планына (алга таба кыска вакытлы планга), яңа редакциядә кыска вакытлы

планны бәян итеп, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, , үзгәрешләр кертергә

2.Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru.веб - адресы буенча урнаштырырга.

1. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта

№1 к постановлению
« _____» _________2018 № _______

# 2017-2019 елларга Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны кыска вакытта гамәлгә ашыру планы

Азнакай шәһәре
2018

## I.Гомуми нигезләмәләр

Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау муниципаль адреслы программасын тормышка ашыруның әлеге кыска вакытлы планы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау муниципаль адреслы программасы турында» 2013 елның 31 декабрендәге 337 номерлы карары белән расланган, (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 4 маендагы 115 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), Россия Федерациясе Торак кодексы белән, "Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында" 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-185-ФЗ номерлы Федераль закон), "Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында" 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы), муниципаль программаны тормышка ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау срокларын аныклау, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча планлаштырылган хезмәт төрләрен һәм (яки) эшләрне ачыклау, капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын раслау турында» (ТР Министрлар Кабинеты редакциясендә) карарлары нигезендә эшләнгән.

## II. Кыска вакытлы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында торак фондын саклау, торгызу һәм сыйфатын күтәрү;

гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру;

күп фатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм.

Кыска вакытлы планның төп бурычлары:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

программаны башкаручыларны сайлап алуның үтә күренмәле, ачык процедураларын эшләү һәм үтәү;

чыдам материалларны һәм ресурсларны саклау технологияләрен кулланып капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләрне һәм комплекслыкны куллану.

Кыска вакытлы планны тормышка ашыру вакыты: 2017-2019 еллар.

2017 елда Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 100,533 мең кв. метр булган 30 күпфатирлы йортта 4452 гражданны куркынычсыз һәм уңайлы яшәү шартлары белән тәэмин итәргә тиеш;

2018 елда Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 72,364 мең кв. метр булган 25 күпфатирлы йортта 3019 гражданны куркынычсыз һәм уңайлы яшәү шартлары белән тәэмин итәргә тиеш;

2019 елда Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 77,396 мең кв. метр булган 29 күпфатирлы йортта 3253 гражданны куркынычсыз һәм уңайлы яшәү шартлары белән тәэмин итәргә тиеш;

Кыска вакытлы планны үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре әлеге Кыска вакытлы планның №1 кушымтасында тәкъдим ителгән.

## III. Кыска вакытлы планда катнашучы Азнакай муниципаль районы торак пунктлары исемлеге

Кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы торак пунктларының Исемлеге район территориясендә Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлүне исәпкә алып формалаштырылды;

Кыска вакытлы планны тормышка ашыруда Азнакай муниципаль районының түбәндәге торак пунктлары катнаша: Азнакай шәһәре, шәһәр тибындагы Актүбә бистәсе, Чалпы, Чемодур , Кәкре - Елга , Зур Сукаеш авыллары.

## IV. Кыска вкытлы планны үтәүнең планнаштырылган күрсәткечләре

Азнакай муниципаль районында 2017-2019елларда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге кв. метр | Эшләр күләме | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2017 | 2018 | 2019 |
| Түбә ремонтлау, шул исәптән җылләтелә һәм җылләтелми торган түбәләрне, түбәгә чыгу | кв. метр | 47609,7 | 14340,40 | 9754,6 | 23514,7 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| юларын үзгәртеп кору | | | | | |
| Йорт эчендәге электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу инженерлык системаларын ремонтлау яки алмаштыру, шул исәптән торак биналарда урнашкан җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге системаларда урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазларны ремонтлау яки алмаштыру, шул исәптән: | кв. метр | 92808,21 | 23810,03 | 27999,28 | 40998,9 |
| электр белән тәэмин итү | кв. метров | 25018,8 | 4077,00 | 5252,9 | 15688,9 |
| җылылык белән тәэмин итү | пог. метров | 43020,08 | 13605,77 | 14534,31 | 14880,00 |
| су белән тәэмин итү | пог. метров | 9538,69 | 1668,43 | 3701,26 | 4169,00 |
| водоотведения | пог. метров | 10473,35 | 2970,89 | 2917,46 | 4585,00 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | пог.метров | 4757,29 | 1487,94 | 1593,35 | 1676,00 |
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | кв. метров | 64171,96 | 18877,58 | 21187,90 | 24106,48 |
| Күп фатирлы йортларның подъездларын ремонтлау | кв. метров | 127,5 | 35,70 | 0 | 91,8 |
| Күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета бәясен дөрес итеп билгеләүне тикшерү үткәрү | штук | 54 | 0 | 25 | 29 |

Кыска вакытлы планга кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры 2/1, 2/2, 2/3 нче кушымталарында китерелгән

## V. Ресурс белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) җирле бюджет акчалары, торак милекчеләре ширкәте әгъзалары, идарәче компанияләр, МУП акчалары тора.

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме:

2017 елда-83 906 690,91 сум, шул исәптән :

Татарстан Республикасы бюджеты-22 642 417,34 сум,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджеты-18 566 020,00 сум,

бина милекчеләренең акчалары – 42 698 273,57сум.

2018 елда-89831236,53 сум, шул исәптән акча:

Татарстан Республикасы бюджеты – 21 908 982,00 сум,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджеты - 18 566 000,00 сум,

бина милекчеләренең акчалары – 49 356 254,53 сум.

2019 елда – 89 343076,65 сум, шул исәптән акча:

Татарстан Республикасы бюджеты – 24 046 712,6 сум,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджеты - 18 566 000,00 сум,

бина милекчеләренең акчалары – 46 730 364,04 сум.

2017-2019 елларда күп фатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрүгә финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Сумма мең сумнарда | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2017 | 2018 | 2019 |
| Түбә ремонтлау, шул исәптән җилләтелә һәм җилләтелми торган түбәләрне, түбәгә чыгу юларын үзгәртеп кору | 71905,129 | 28436,232 | 16287,857 | 27181,040 |
| Йорт эчендәге электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу инженерлык системаларын ремонтлау яки алмаштыру, шул исәптән торак биналарда урнашкан җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге системаларда урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазларны ремонтлау яки алмаштыру, шул исәптән: | 97884,137 | 29856,762 | 33422,747 | 31122,998 |
| электр белән тәэмин итү | 4049,381 | 1374,381 | 866,721 | 1845,000 |
| җылылык белән тәэмин итү | 59519,537 | 19790,963 | 24348,988 | 16779,490 |
| су белән тәэмин итү | 9732,997 | 1667,549 | 2808,270 | 3263,758 |
| водоотведения | 16819,938 | 5308,370 | 4019,640 | 5239,868 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | 7762,282 | 1715,499 | 1379,128 | 3994,880 |
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | 81809,03 | 24688,535 | 34994,316 | 26207,809 |
| Күп фатирлы йортларның подъездларын ремонтлау | 214,400 | 94,400 | 0 | 120,000 |
| электр белән тәэмин итү | 2524,126 | 830,759 | 847,049 | 846,318 |
| Күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета бәясен дөрес итеп билгеләүне тикшерү үткәрү | 5080,102 | 0 | 2541,147 | 2538,955 |
| Күпфатирлы йортны энергетик тикшерү үткәрү | 651,885 | 0 | 651,885 | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Техник паспортлар әзерләү буенча эшләр үткәрү | 2412,187 | 0 | 1086,232 | 1325,955 |
| Барлыгы: | | **83906,690** | **89831,237** | **89343,076** |

№ 3/1, 3/2, 3/3 кушымталар

## VI. Капиталь ремонт буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясе

Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясе күләме, укапиталь ремонт фонды акчалары хисабына төбәк операторы тарафыннан, күпфатирлы йортта биналарның гомуми мәйданының 1 кв. метрына исәпләнгән капиталь ремонт өчен түләүнең минималь күләменнән чыгып түләнергә мөмкин. 2017-2019 елларга формалашкан күләме 14 мең сум тәшкил итә.

Капиталь ремонт буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясенең артуы, шулай ук кыска сроклы планда каралмаган хезмәт һәм (яки) эшләр өчен түләү күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең капиталь ремонт өчен взнос рәвешендә түләнә торган акчалары хисабына башкарыла.

## VII. Кыска вакытлы планны тормышка ашыру механизмы

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты:

Татарстан Республикасы төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба министрлык тексты буенча) региональ программаны гамәлгә ашыруның муниципаль кыска вакытлы планнарын һәм федераль закон нигезендә финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне раслаучы документларны формалаштыра һәм җибәрә;

министрлыкка норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен раслаучы башка документлар тапшыралар;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнаша;

КС-2 формасы буенча башкарылган эшләр актларын килештерәләр;

торак законнары нигезендә, әлеге кыска сроклы план белән билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга җирле бюджет акчаларын күчерәләр;

күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау өчен расланган чыгымнар сметасында каралмаган очраклардан тыш, капиталь ремонт буенча эшләрне кабул итү актларын килештерәләр, шулай ук аннан арткан очракта да;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тота;

Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру максатларында мәгълүматлар базасын булдыралар һәм актуаль хәлдә саклап торалар;

министрлыкка Фондка хисап формалаштыру өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр тапшыралар.

ТСЖ, УК, МУП-идарәче оешмалар:

капиталь ремонт буенча эш күләменә дефект исемлекләре, тикшерү актлары килештерәләр;

дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алган проект документларын әзерләүне тәэмин итә.

Министрлык раслаган тәртип нигезендә сайлап алуны оештыра;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процессында катнашалар;

капиталь ремонт объектларына өстәп торалар;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтның вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда, шулай ук аларны файдалануга тапшыру актларына капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларын имзалау хокукы белән кабул итүдә катнашалар.

Бина милекчеләре:

капиталь ремонт буенча эш күләменә дефект исемлекләре, тикшерү актлары килештерәләр;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтның вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда, шулай ук аларны файдалануга тапшыру актларына капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларын имзалау хокукы белән кабул итүдә катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы дамаларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне подрядчы килешүендә билгеләнгән срокларда башкаруны тәэмин итәләр;

башкарылган эшләр актларын КС-2,КС-3 формасы буенча формалаштыралар;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Кыска вакытлы планны планлаштыру, куллану, контрольдә тоту һәм мониторинглау "Торак фонды мониторингы"бердәм мәгълүмат продуктында гамәлгә ашырыла.

## VIII. Күпфатирлы йортларның гомуми милеген капиталь ремонтлау эшләрен башкару өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе

Подрядчы оешмалар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 1 июлендәге 615 номерлы карары нигезендә сайлап алына.

"Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару өчен подрядчы оешмаларны җәлеп итү тәртибе һәм күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма функцияләрен үтәү максатларында товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны гамәлгә ашыру тәртибе турында".